ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

КАРАР

2021 елның «28» апреленнән № 207

Макулатура, пластик шешәләр, полиэтилен һәм чүпрәк җыю буенча
«Чиста авыл синнән башлана!» бәйгесенең
нигезләмәсен раслау турында

Торак пунктларның экологик торышын яхшырту, ишегалларын һәм урамнарны чистарту максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта итеп бирелгән макулатура, пластик шешәләр, полиэтилен һәм чүпрәк җыю буенча «Чиста авыл синнән башлана!» бәйгесенең нигезләмәсен расларга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына конкурста җиңүчеләрне бүләкләү өчен 30 000 (утыз мең) сум күләмендә акча табарга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://www.novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсъәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Л.К. Исхакова

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның «28» апрелендәге
№ 207 карары белән расланды

Макулатура, пластик шешәләр, полиэтилен һәм чүпрәк җыю буенча
«Чиста авыл синнән башлана!» бәйгесенең
НИГЕЗЛӘМӘСЕ

Макулатура, пластик шешәләр, полиэтилен һәм чүпрәк җыю буенча муниципаль бәйге (алга таба - Бәйге) үткәрү турында әлеге нигезләмә аны оештыру һәм үткәрү максатларын, бурычларын, тәртибен билгели.

## 1. Гомуми нигезләмәләр

Бәйге Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районында экологик хәлне яхшыртуга юнәлтелгән.

## 2. Максат һәм бурычлар

2.1. Бәйге Яңа Чишмә муниципаль районы торак пунктларының ишегалларын һәм урамнарын макулатура, пластик шешәләр, полиэтилен һәм чүпрәкләрдән чистарту максаты белән үткәрелә.

2.2. Бәйгенең бурычлары:

муниципаль бюджет белем бирү учреждениеләре (алга таба-МБББУ) укучыларын туган авылны экологик чистарту буенча гамәли эшчәнлеккә җәлеп итү;

яшь буында әйләнә-тирә мохитнең чисталыгы өчен җаваплылык хисе формалаштыру;

район халкы арасында культура дәрәҗәсен күтәрү;

икенчел чималны рациональ куллану.

3. Бәйгедә катнашучылар

3.1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль бюджет белем бирү учреждениеләре сыйныфлары. Бәйге 1-5 сыйныф һәм 6-11 сыйныф укучылары арасында аерым үткәрелә.

## 4. Бәйгене үткәрү тәртибе һәм сроклары

4.1. Бәйгене үткәрү сроклары
- 2021 елның 28 апреленнән
- 2021 елның 31 маена кадәр.

4.2. Макулатура, пластик шешәләр, полиэтилен һәм чүпрәк җыю Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы белем бирү учреждениеләре сыйныфлары тарафыннан башкарыла.

4.3. Картон һәм кәгазь (газета, А4, журналлар) җыю аерым башкарыла.

4.4. Пластик шешәләр һәм полиэтилен җыю чүп-чар өчен пластик капчыкларга аерым башкарыла.

4.5. Макулатура, пластик шешәләр, полиэтилен һәм чүпрәк массасын үлчәүне икенчел чималны кабул итү пунктлары башкара.

4.7. Макулатура һәм пластик шешәләр чыгаруны мәгариф оешмалары башкара.

## 5. Бәйгедә катнашучыларны бүләкләү

Бәйгедә җиңүчеләр (сыйныф) икенчел чималны кабул итү пунктында бәйгедә катнашучы укучылар исеменә бирелгән икенчел чималны тапшыруны раслаучы документлар (кабул итү турында накладная) нигезендә билгеләнә.

Урыннар икенчел чималны җыйган һәм тапшырган сыйныфлар арасында бүленә:

1-5 сыйныфлар - кимендә 600 кг.

6-11 сыйныфлар - кимендә 1000 кг.

Һәр төркемдә бүләкләү:

1 урын - 7000 сум

2 урын - 5000 сум

3 урын - 3000 сум.